КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 29 май г.Казань № 750

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 12 июнь, 427 нче карары белән расланган Халык сәнгать һөнәрләре тармагында «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм физик затларга булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 12 июнь, 427 нче карары белән расланган Халык сәнгать һөнәрләре тармагында «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм физик затларга булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

8.8 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

9.5 пунктның беренче абзацында «Бирелгән грант» сүзләрен «Грант акчасы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер–министры А.В.Песошин